**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**23.06.2023ел** **№ 103**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 24 февралендәге 175 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 06 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советының 24.02.2014 № 175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 19 статьясындагы 3 өлешенә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләре белән алыштырып үзгәреш кертергә.
2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**башлыгы башлыгы** **И.А. Галимов**